**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2023 елның 13 марты 37-РС номер

**КАРАР**

**«2023 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2022 елның 23 декабрендәге 104-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары кушымтасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Лаеш муниципаль районы Советының 2010 елның 23 июлендәге 24 номерлы карары белән расланган Лаеш муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар кылды.:

1. «2023 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2022 елның 23 декабрендәге 104-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары кушымтасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (Кушымта).

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны районның җирле үзидарә органнары белән законлылык, хокук тәртибе һәм үзара хезмәттәшлек буенча комиссиягә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**

Татарстан Республикасы Лаеш
муниципаль районының 2023 елның 13
мартындагы 37-РС номерлы карарына
кушымта

**«2023 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2022 елның 23 декабрендәге 104-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары кушымтасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

| № п/п | Муниципаль мөлкәт исеме | Урыны | Бина, төзелеш, корылма мәйданы (кв.м) | Җир участогы мәйданы (кв.м) | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Бакча йорты (кадастр номеры 16:24:257001:518) һәм кадастр номеры 16:24:257001:26 булган җир участогы | ТР, Лаеш муниципаль районы, Орел авыл җирлеге, коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте «Механик", 26 йорт | 67,8 | 615,0 | 2023 ел дәвамында |